ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 76 от «19» 02 2021 г.

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы
Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы гамәлгә куючы оешмалар
җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен)
аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 елның 29 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **к а р а р б и р ә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 октябрендәге 1324 нче карары белән расланган Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гамәлгә куючы оешмалар җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.9 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аттестация комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аттестация уздыру көнендә тавыш бирүдә катнашкан рәис, рәис урынбасары, комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана».

1.2. Нигезләмәгә IV.« Аттестация комиссиясен формалаштыру» бүлеген өстәргә:

IV. «Аттестация комиссиясен формалаштыру»

4.1. Аттестация комиссиясе аттестация комиссиясе рәисеннән, аттестация комиссиясе Рәисенең ике урынбасарыннан, аттестация комиссиясе секретареннән һәм аттестация комиссиясе әгъзаларыннан тора.

Аттестация комиссиясе рәисе:

1) аттестация комиссиясе эше белән җитәкчелек итә;

2) аттестация комиссиясе утырышларында рәислек итә;

3) аттестация комиссиясе эше вакытында педагогик этика нормаларын үтәү өчен җавап бирә;

0000010786

4) аттестация комиссиясе эше сыйфаты, кабул ителә торган карарларның объективлыгы, аның эш нәтиҗәләре буенча документларны үз вакытында рәсмиләштерү өчен җавап бирә.

Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары, аттестация комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен башкара.

Аттестация комиссиясе секретаре:

1) календарь елга аттестация комиссиясе утырышларын үткәрү графигын эшли;

2) аттестация комиссиясе утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында аттестация комиссиясе әгъзаларына хәбәр итә;

3) аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә.

Аттестация комиссиясе әгъзалары:

1) аттестация комиссиясе эшендә катнашалар;

2) карала торган мәсьәлә буенча үз фикерләрен әйтәләр (аерым фикер булганда-язма рәвештә);

3) аттестация комиссиясе эше вакытында педагогик этика нормаларын үтәү өчен җавап бирәләр;

4) кабул ителгән карарларның объективлыгы һәм компетентлыгы өчен җавап бирәләр;

5) аттестация комиссиясе секретарен аттестация комиссиясе утырышында җитди сәбәпләр аркасында утырыш үткәрү датасына ике көннән дә ким булмаган очракта кисәтәләр.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗәҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов